# ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР

Татар укучысы Роза Хәбибуллина әсәрләре белән елдан-ел ныграк таныша бара. Ул әдәбиятка оптимистик рухлы повестьлары белән килеп керде, һәм аларны яратып укыйлар.

Авторның әсәрләренә балаларча самимилек хас, ул каләмен саф хис-тойгыларына манып яза. Адәм балалары өчен андый кичерешләрдән дә кадерлерәк нәрсә юк. Намус, вөҗдан, игелеклелек, мәрхәмәтлелек, фидакярлек, мәхәббәт, тугрылык кебек бөек тойгыларны кеше күңелендәге саф, табигый хәлләр генә мәңге сугарып тора.

Р. Хәбибуллина иҗаты кешенең балачак чорыннан җитлегүенә таба барган иң мөһим баскычлары буйлап күтәрелә кебек. «Калморза» повестендагы вакыйгалар дүрт яшьлек Илсөяр күзе белән сурәтләнә башлап, аңа унбиш яшь тулгач төгәлләнә. Бөек Ватан сугышы чоры һәм аннан соңгы авыл тормышын без ул күргәнчә, ул аңлаганча кабул итәбез. «Миләш елы» повесте беренче саф тойгыларның кайнар мәхәббәткә әверелүе һәм аның төрле сынаулар аша үтеп, җиңеп чыгуы хакында. Р. Хәбибуллина «Чишмә башы» һәм «Яшьлегем серләре» дигән

әсәрләрен гаилә темасына багышлады. Аның беренчесе катнаш никахның аяныч нәтиҗәләргә китерүен күрсәтә. Татар егетенең рус кызына өйләнүе икесенең бәхетсезлегенә әверелеп, аларның баласы, оныклары тормышында да фаҗигале язмыш булып дәвам итә. «Яшьлегем серләре»ндә язучы гаиләне саклаучы бөек көч мәхәббәт икәнлеген, бу хисне саклау өчен, хатынның да, ирнең дә үз холыкларындагы тискәре сыйфатларны йөгәнләргә тиешлеген җанлы вакыйгаларда гәүдәләндерә.

Роза Хәбибуллинаның иҗатына хас тагын бер үзенчәлекне искәртеп үтәсе килә. Аның һәр әсәре чынбарлыктан, кешеләр тормышыннан алынган. Ул үзен кызыксындырган хәлләрне, анда катнашучыларны, күңелендәге хис-кичерешләре, уй-фикерләре белән җанландырып, укучылар хөкеменә тапшыра. Аның Татарстан китап нәшриятында чыгып килүче әлеге китапта урын алган «Мулла килене» һәм «Зәйтүн илендә» әсәрләре, алда искәртелгәнчә, тормыш «үзе язган» чынбарлык вакыйгаларга нигезләнгән. Бу ике әсәр авторның гражданлык позициясе ныгуын күрсәтә. Аларда ил тарихы, иҗтимагый-сәяси вакыйгалар, бүгенге чынбарлык югары әхлакый принциплардан чыгып бәяләнә. XX гасырның утызынчы-кырыгынчы еллары илебез тарихына тетрәндергеч репрессияләр, халыкның иң яхшы улларын һәм кызларын юк итү чоры булып кереп калган. Р. Хәбибуллина

«Мулла килене» әсәрендә әнә шул коточкыч фаҗиганең аерым кешеләр язмышында уйнаган ролен сурәтли. 1930 елда Миргаяз мулланы, халыкның яклап торуына карамастан, хатыны, өч улы белән туган авылыннан удмурт җиренә урман кисәргә сөрәләр. Хәзрәт моны Аллаһының сынавы дип бәяли, төшенкелеккә бирелмәскә өнди. Әсәр татар халкының оптимист булуына, авырлыклар алдында беркайчан да баш имәвенә, чиста күңелле һәм хезмәт сөючән булуына инандыра. Әсәр ил тормышының җитмеш ел чамасы дәверен колачлый. Анда репрессия заманнары, сугыш елларының ачы газабы, тылда калган хатын-кызлар, балалар һәм үсмерләрнең авыр тормышы, тырыш хезмәте бәян ителә. Халык сугыштан соңгы авыл тормышының газап-михнәтләрен уза. Повесть сюжеты, шул чорлар аша урап, бүгенге көннәргә кадәр килеп җитә. Әсәрдә Маһинур һәм улы Ирек, Ирекнең якын дусты Бәхтияр һәм аның әнисе Хөрриянең гыйбрәтле язмышлары аша аналар һәм балалар мөнәсәбәтләре дә бик уңышлы сурәтләнә. Повесть эчтәлеге бүгенге укучы өчен бик тә кызыклы, гыйбрәтле булыр.

«Зәйтүн илендә» хикәясе бүген без яшәгән чорның фаҗигале хәлләренә багышланган. Эштән кыскартылулар, аннары, бизнес белән шөгыльләнмәкче булып, фатир сату һәм компаньон тарафыннан алданып, акчадан да, фатирдан да колак кагу хәлләре кешеләрне үлемгә китереп җиткерә. Әсәрнең

төп герое Нурия, балаларын фатирлы итү максаты белән, Грециягә эш эзләргә китә... Илнең бәхетсез балалары кайларда гына йөрми, нинди генә газап-михнәтләр күрми! Туксанынчы елларда башланган бу фаҗигале хәлләрнең бүген дә беткәне юк. Чарасызлык, гаделсезлек күп кешеләрнең язмышын әйләндереп ташлый. Бу хикәя үзенең социаль үткенлеге белән укучылар күңелен яулар дип ышанам.

Роза Хәбибуллина иҗатында билгеле бер яңарыш сизелә. Аны язучының ил, халык яшәешендәге иҗтимагый-сәяси вакыйгаларга тирәнрәк үтеп керүе дип аңларга кирәк.

*Фоат Садриев,*
язучы, Г. Тукай исемендәге
Дәүләт премиясе лауреаты

# МУЛЛА КИЛЕНЕ

*(Повесть)*

